| ГОРОДСКОЙ СОВЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ ШӘҺӘР СОВЕТЫ |
|---|---|

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

08 ноябрь, 2018 ел № 27/5

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турында Нигезнамәгә үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясенең Бюджет кодексына, 2018 елның 19 июлендәге «Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм "Россия Федерациясе Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе закон актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында" Федераль законның 4 маддәсенә үзгәрешләр кертү хакында» 222-ФЗ саны Федераль законга, Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставының 28 маддәсенә нигезләнеп,

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Шәһәр Советының 2013 елның 29 августындагы 26/6 санлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турындагы Нигезнамәгә (Шәһәр Советының 2013 елның 19 декабрендәге 28/7, 2014 елның 16 октябрендәге 33/6, 2015 елның 15 апрелендәге 39/6, 2015 елның 22 октябрендәге 2/14, 2016 елның 24 февралендәге 6/6, 2017 елның 24 октябрендәге 20/5, 2018 елның 21 февралендәге 23/7 санлы Карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) 4 маддәнең 3 өлешендәге 3 пунктны гамәлдән чыккан дип танырга;

2) 4 маддәнең 3 өлешендәге 7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7) товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алуны формалаштыру, үтәү һәм гамәлгә ашыруны контрольдә тоту тәртибен билгеле.»;

3) 4 маддәнең 6 өлешендәге 10 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10) максатчан билгеләнеше булган бюджетара субсидияләр, субвенцияләр һәм башка бюджетара трансфертларның, шулай ук Россия Федерациясе Бюджет кодексы белән билгеләнгән башка субсидияләр һәм бюджет инвестицияләренең үтәлешен, аларны биргәндә билгеләнгән шартларны, максатларны һәм тәртипләрне үтәүне тәэмин итә;»

4) 5 маддәнең 6 өлеше беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Бюджет акчаларын алучы казна учреждениесе тарафыннан муниципаль контрактлар, башка килешүләр төзү нәтиҗәсендә бюджет йөкләмәләре үтәлмәвенә китергән элегрәк бирелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары бюджет средстволарының баш бүлүчесе (бүлүчесе) тарафыннан киметелгән очракта, , казна учреждениесе Россия Федерациясенең дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында законнары нигезендә килештерүне, шул исәптән, аларның бәясе һәм (яки) үтәү сроклары һәм (яисә) товар (эш, хезмәт күрсәтү) күләме (саны), башка килешүләр буенча тәэмин итәргә тиеш.»;

5) 8 маддәнең 3 өлеше 4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) муниципаль милек объектларына бюджет инвестицияләрен гамәлгә ашыру;»;

6) 8 маддәнең 3 өлеше 6 пунктны гамәлдән чыккан дип танырга;

7) 8 маддәнең 8 өлеше 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу;»;

8) 8 маддәнең 9 өлеше беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүне сатып алу Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезләмәләрен исәпкә алып, дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында Россия Федерациясе законнары нигезендә гамәлгә ашырыла.»;

9) 8 маддәнең 12 өлеше беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Юридик затларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләргә бирелүче субсидияләрдән тыш), шәхси эшмәкәрләргә, шулай товарлар җитештерүче һәм хезмәт күрсәтүче физик затларга субсидияләр товарлар (җиңел автомобильләр һәм мотоцикллар, Россия Федерациясе территориясендә үстерелгән виноградтан шәраб продукциясе җитештерүдән башка продакциз товарларыннан тыш) җитештерү (сату) чыгымнарын финанс белән тәэмин итү һәм (яки) алынмаган

керемнәрне кайтару максатында түләүсез һәм кире кайтарылмый торган нигездә бирелә.»;

10) 8 маддәнең 12.1 өлешендә «Шәһәр Советы карары белән» сүзләрен «Башкарма комитет карары белән» сүзләренә үзгәртергә;

11) 8 маддәнең 12.2 өлешен яңа редакциядә бәян итәргә:

«12.2. Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78 маддәсе 1 пунктында күрсәтелгән юридик затларга Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78 маддәсендә каралган субсидияләрне биргәндә, товарлар җитештерүгә (реализацияләүгә) бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә, эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә килешү төзегәндә һәм (яисә) норматив хокукый актларга, аларны бирүне җайга сала торган муниципаль хокукый актларга кертелә торган мәҗбүри шарт булып, алынган средстволарга чит ил валютасын сатып алмау тора (Россия Федерациясе валюта законнары нигезендә югары технологияле чит ил җиһазларын, чимал һәм комплектлау әйберләрен сатып алганда, шулай ук юридик затларга субсидияләр бирүне җайга сала торган муниципаль хокукый актлар белән каралган тәртиптә башка операцияләрдән тыш).»

12) 8 маддәнең 14.1 өлешендәге икенче абзацны түбәндәге эчтәлектәге җөмлә белән тулыландырырга:

«Әгәр Россия Федерациясе законнары нигезендә капиталь төзелеш объекты өчен инвестицияләрнең нигезләнешен әзерләү мәҗбүри булса, мондый капиталь төзелеш объектларына карата күрсәтелгән карарлар шул исәптән Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән тәртиптә инвестицияләрне нигезләү һәм аның технологик һәм бәя аудиты нәтиҗәләре, шулай ук расланган проектлау биреме нигезендә кабул ителә.»;

13) 8 маддәнең 15 өлешенәге түбәндәге эчтәлектәге бишенче абзацны өстәргә:

«Әгәр Россия Федерациясе законнары нигезендә капиталь төзелеш объекты өчен инвестицияләрнең нигезләнешен әзерләү мәҗбүри булса, мондый муниципаль милек капиталь төзелеш объектларына бюджет инвестицияләрен әзерләү һәм гамәлгә ашыру турында карар шул исәптән Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә әзерләнгән инвестицияләр нигезләү һәм аның технологик һәм бәя аудиты нәтиҗәләре, шулай ук проектлауга расланган бирем нигезендә кабул ителә.

Шәһәр бюджеты средстволары исәбеннән инвестицияләрне нигезләүгә бюджет инвестицияләрен гамәлгә ашыру турында карарлар кабул итү, технологик һәм бәя аудиты үткәрү һәм әлеге бюджет инвестицияләрен гамәлгә ашыру тәртибе Башкарма комитет тарафыннан билгеләнә.»;

14) 8 маддәне түбәндәге эчтәлектәге 15.2 өлеше белән тулыландырырга:

«15.2. Шәһәр бюджетында бюджет һәм автоном учреждениеләргә, муниципаль унитар предприятиеләргә әлеге учреждениеләр һәм предприятиеләр тарафыннан муниципаль милек капиталь төзелеш объектларына капитал салуларны гамәлгә ашыруга яки күчемсез милек объектларын муниципаль милеккә сатып алуга, киләчәктә әлеге учреждениеләрдә оператив идарә итү хокукындагы төп чараларның яисә әлеге предприятиеләрдә оператив идарә итү яисә хуҗалык алып бару хокукындагы төп чараларның, шулай ук әлеге өлештә күрсәтелгән карарлар нигезендә күрсәтелгән предприятиеләрнең устав фонды бәясенең артуына китерүче, субсидияләр каралырга мөмкин (алга таба әлеге пунктта - муниципаль милек объектына капитал салулар).

Әлеге өлештә каралганча муниципаль милек объектларына капитал салуларга субсидияләрне гамәлгә кую өчен бюджет ассигнованиеләре бирү турында карарлар кабул итү һәм аларны бирү тәртибе Башкарма комитет тарафыннан башкарыла

Әлеге өлештә каралганча субсидия бирү Башкарма комитет һәм бюджет яисә автоном учреждение, муниципаль унитар предприятие арасында төзелә торган субсидия бирү турындагы килешү нигезендә һәм Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78.2 маддәсе 4 пунктының ундүртенче абзацындагы нигезләмәләрне исәпкә алып, расланган бюджет йөкләмәләре лимитының гамәли вакытында тормышка ашырыла.

Россия Федерациясе законнары нигезендә капиталь төзелеш объекты өчен инвестицияләрнең нигезләнешен әзерләү мәҗбүри булса, муниципаль милек капиталь төзелеш объектларына капитал салуларны гамәлгә ашыруга субсидияләр бирү турындагы карарлар шул исәптән Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә инвестицияләрне нигезләү һәм аның технологик һәм бәя аудиты нәтиҗәләрен, шулай ук расланган проектлау биреме нигезендә кабул ителә.

Инвестицияләр нигезләүне әзерләүгә субсидияләр бирү, аңа шәһәр бюджетыннан технологик һәм бәя аудиты үткәрү һәм күрсәтелгән субсидияләрне бирү тәртибе, бирү сроклары, шартлары һәм таләпләрен дә кертеп, Башкарма комитет тарафыннан билгеләнә.»;

15) 8 маддәнең 18 өлешен түбәндәге эчтәлектәге алтынчы абзац белән тулыландырырга:

«Россия Федерациясе законнары нигезендә капиталь төзелеш объекты өчен инвестицияләрнең нигезләнешен әзерләү мәҗбүри булган очракта, әлеге өлешнең икенче абзацында күрсәтелгән карарлар мондый капиталь төзелеш объектларына карата шул исәптән Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән инвестицияләр нигезләү һәм аның технологик һәм бәя аудиты нәтиҗәләре, шулай ук расланган проектлау биреме нигезендә кабул ителә.»;

16) 13 маддәнең 2 өлешендәге унынчы абзацын түбәндәге эчтәлектә бәян итәргә:

«Агымдагы финанс елы башында хисап финанс елында кулланылмаган муниципаль юл фондының бюджет ассигнованиеләре күләмендәге бюджет средстволары агымдагы финанс елындагы муниципаль юл фондының бюджет ассигнованиеләрен арттыруууга юнәлтелә, шулай ук Шәһәр Советы карары белән билгеләнгән күләмдә агымдагы финанс елында вакытлыча касса өзеклекләрен каплау һәм муниципаль берәмлек исеменнән төзелгән товарлар белән тәэмин итүгә, эшләр башкаруга, әлеге муниципаль контрактларның шартлары нигезендә хисап финанс елында түләнергә тиешле хезмәтләр күрсәтүгә бюджет ассигнованиеләрен арттыруга, Шәһәр Советының шәһәр бюджеты хакындагы карары белән, хисап елында алар субсидия алучылапның акчалата йөкләмәләрен түләү өчен кирәкле сумма чикләрендә, күрсәтелгән субсидияләр финанс чыганагы булган очракта, күрсәтелгән максатларда файдаланылмаган бюджет ассигнованиелере суммасын ягыннан тәэмин итү чыганагы булып күрсәтелгән субсидияләр алучыларның акчалата йөкләмәләрен әлеге максатларга файдаланылмаган бюджет ассигнованиеләренең калган суммасыннан артмаган күләмдәюридик затларга бюджет ассинованиеләренә юнәлтелергә мөмкин.»;

17) 19 маддәнең 2 өлешендәге 3 пунктны гамәлдән чыккан дип танырга;

18) 26 маддәнең 3 өлешендәге өченче абзацны гамәлдән чыккан дип танырга;

19) 27 маддәнең 1 өлешендәге 1 пунктны түбәндәге эчтәлектә бәян итәргә:

«1) шәһәрнең бюджет һәм салым сәясәтенең төп юнәлешләре;»;

20) 27 маддәнең 1 өлешендәге 8.1 пунктны түбәндәге эчтәлектә бәян итәргә:

«8.1) шәһәр бюджеты керемнәре чыганаклары реестры;»;

21) 30 маддәнең 4 өлешендәге беренче һәм икенче абзацларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Җыелма бюджет язмасын төзү һәм алып бару тәртибе белән җыелма бюджет язмасы күрсәткечләрен һәм бюджет йөкләмәләре лимитларын бюджет средстволарының баш бүлүчеләре, бүлекләре, бүлекчәләре, максатчан статьялары (дәүләт (муниципаль) программаларының һәм эшчәнлекнең программадан тыш булмаган юнәлешләре), бюджет чыгымнары классификацияләре төрләре (төркемнәре һәм төркемчәләре) буенча раслау карала.

Җыелма бюджет язмасын төзү һәм алып бару тәртибе белән бюджет чыгымнары классификациясенең чыгымнар төрләре төркемнәре, төркемчәләре (төркемнәре, төркемчәләре һәм элементлары) буенча бюджет йөкләмәләре лимитларын раслау, шул исәптән бюджет чыгымнарының төрле максатчан статьялары һәм (яисә) бюджет чыгымнары төрләре буенча дифференция белән раслау, каралырга мөмкин.»;

22) 33 маддәнең 3 өлешен түбәндәге эчтәлектә бәян итәргә:

«3. Бюджет акчаларын алучы үзенә җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә бюджет йөкләмәләрен кабул итә.

Бюджет акчаларын алучы бюджет йөкләмәләрен муниципаль контрактлар, физик һәм юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр белән башка килешүләр төзү юлы белән яисә закон, башка хокукый акт, килешү нигезендә кабул итә.»;

23) 34 маддәнең 2 өлешендәге икенче абзацны түбәндәге эчтәлектә бәян итәргә:

«Бюджет йөкләмәләре чыгымнары һәм лимитлары буенча бюджет язмасы күрсәткечләре, Россия Федерациясе Бюджет кодексының 190 һәм 191 маддәләрендә каралган очраклардан тыш, чираттагы финанс елы башланганчы, ведомствога караган бүлүчеләргә һәм (яисә) бюджет акчаларын алучыларга җиткерелә.»;

24) 34 маддәнең 3 пунктын түбәндәге эчтәлектә бәян итәргә:

«3. Бюджет язмаларын төзү һәм алып бару тәртибе бюджет акчаларын баш бүлүченең (бүлүченең) расланучы бюджет йөкләмәләре лимитларвының чыгымнар төрләре буенча төркемчәләргә (элементларга) аныклауны гамәлгә ашыру хокукын яисә бурычын билгеләргә мөмкин..»;

25) 36 маддәнең 2 өлешендәге дүртенче абзацны түбәндәге эчтәлектә бәян итәргә:

«Җитәкчесе казна учреждениесенең бюджет сметасын раслау тәртибе нигезендә раслау хокукына ия булган казна учреждениесенең бюджет сметасы күрсәткечләре элементлары (төркемчәләр һәм элементлар) кодлары буенча күрсәтелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә, шулай ук тиешле төркемнәр (статьялар) статьялары (ярдәмче статьялары) кодлары буенча өстәмә рәвештә дәүләт идарәсе секторы операцияләре классификациясенең бюджет йөкләмәләре чикләрендә детальләштерелергә мөмкин.»;

26) 37 маддәнең 2 өлешен түбәндәге эчтәлектә бәян итәргә:

«2. Финанслауның чик күләме бюджет акчаларын баш бүлүчегә, бүлүчегә һәм алучыга карата ай саен яки квартал саен, яйсә агымдагы финанс елы башыннан арта баручы нәтиҗә белән бюджет акчаларын баш бүлүчеләрне, бүлүчеләрне һәм алучыларны финанслауга гаризалар нигезендә билгеләнә.»

27) 48 маддәнең 3 өлешендәге икенче абзацны түбәндәге эчтәлектә бәян итәргә:

«Эчке муниципаль финанс контроле буенча эчке муниципаль финанс контроле органнары вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибе эчке муниципаль финанс контроле буенча тикшерү, ревизия һәм тикшерүләр үткәрү нигезләрен һәм тәртибен, шул исәптән аларны үткәрү, үткәрү периодларын, эчке муниципаль финанс тикшерүе органнары вазыйфаи затларының хокуклары һәм бурычлары турында карарлар кабул итәргә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген, контроль объектларын (аларның

вазыйфаи затларын,) хокукларын һәм бурычларын (шул исәптән эчке муниципаль финанс тикшерүе органнарының вазыйфаи затлары тарафыннан гамәлгә ашырыла торган тикшерүләрне, ревизияләрне һәм тикшерүләрне оештыру-техник тәэмин итү буенча) билгеләргә тиеш.».

2.Әлеге Карар рәсми бастырылган көненнән үз көченә керә, 12-15 пунктлар өчен гамәлгә керү вакыты – 2019 елның 01 гыйнварыннан соң.

3.Әлеге Карарның үтәлешен тикшереп торуны Шәһәр Советының социаль-икътисадый үсеш мәсьәләләре һәм бюджет буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Шәһәр Хакиме — Н.Г. Мәһдиев

ГОРОДСКОЙ СОВЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ ШӘҺӘР СОВЕТЫ
ПРОТОКОЛЬНАЯ ЧАСТЬ
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ